**Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы**
**Починок Кучук авыл җирлеге башлыгы**

# КАРАРЫ

**2023 елның 25 октябре** **№ 8**

**Кукмара муниципаль районы Починок-Кучук авыл җирлегенең Иске Кенә авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены үткәрүне билгеләү турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы һәм Кукмара муниципаль районы Починок Кучук авыл җирлеге Уставының 22 статьясы нигезендә карар бирәм:

1. 2023 елның 18 ноябренә 17 сәгать 00 минутка Кукмара муниципаль районы Починок Кучук авыл җирлегенең Ике Кнә авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыены үткәрүне билгеләргә. Гражданнар җыенын Иске Кнә авылы, Октябрь урамы, 44А йорты адресы буенча урнашкан авыл клубы бинасында үткәрергә.

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга: «Сез 2024 елда Кукмара муниципаль районының Починок Кучук авыл җирлеге Иске Кнә авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, 1 һәм 2 төркем инвалидларыннан; көндезге уку формасы буенча укучы укучылар һәм студентлардан (курсантлардан); 80 яшькә җиткән һәм аннан өлкәнрәк затлардан; Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә сроклы хәрби хезмәткә чакырылган затлардан; Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә хәрби хезмәткә чакырылган затлар һәм аларның гаилә әгъзаларыннан кала, 1000 сум күләмендә үзара салым кертү белән һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

- кышын-җәен урам юл челтәрен карап тоту (ягулык-майлау материаллары, запас частьләр сатып алу, килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү, смета һәм техник күзәтчелек өчен түләү);
- урам юлларына вак таш җәю (проект-смета документлары, техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру, вак таш сатып алу, ташу һәм җәю, килешү буенча эшләр өчен түләү);
- су башнясын, су белән тәэмин итү челтәрен карап тоту һәм ремонтлау, суэтем башнясын коймалау (килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү, смета һәм документлар өчен түләү);
- урам утларын карап тоту (комплектлау материаллары сатып алу һәм килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү, смета һәм документлар өчен түләү);

- территорияне төзекләндерү һәм карап тоту (сатып алу, ташу, төзекләндерү, килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү, смета, техник күзәтчелек һәм документлар өчен түләү);

- тракторны карап тоту (смета һәм документлар өчен түләү, ягулык-майлау материаллары, запас частьләр, комплектлау әйберләре сатып алу, тракторчы хезмәтләре);

- янгынга каршы җиһазлар, савытлар һәм комплектлау җиһазларын сатып алу, урнаштыру һәм карап тоту (килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү, смета, техник күзәтчелек һәм документлар өчен түләү);

- Иске Кнә авылы чишмәләрен төзекләндерү һәм карап тоту (проект-смета документлары, техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру, материал сатып алу, ташу, килешү буенча эшләр өчен түләү);

- спорт инвентаре сатып алу (смета һәм документлар өчен түләү);

- гидротехник корылмаларны (Синерь буасы) төзекләндерү һәм карап тоту, гидротехник корылмаларга янгын техникасы керү мәйданчыгын ясау (Синерь буасы) (проект-смета документлары һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру, материал сатып алу, ташу, вак таш җәю, килешү буенча эшләр өчен түләү);

- видеокүзәтү системасы сатып алу һәм урнаштыру (проект-смета документлары, килешү буенча эш һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү);

- вак таш җәеп, юллардагы чокырларны ремонтлау (вак таш сатып алу, ташу һәм җәю, килешү буенча эшләр өчен түләү, смета һәм техник күзәтчелек өчен түләү);

- зиратының территориясен төзекләндерү һәм карап тоту (инвентарь сатып алу, килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү, смета, техник күзәтчелек һәм документлар өчен түләү);

- Иске Кня авылында җир өсте газүткәргечен реконструкцияләү (смета һәм техник күзәтчелек өчен түләү, сатып алу, ташу, килешү буенча эшләр өчен түләү)

- Починок Кучук авыл мәдәният йортын төзекләндерү һәм карап тоту (театр-сәхнә костюмнары, инвентарь, мультимедия һәм тавыш җиһазлары, акустик системалар һәм комплектлау материаллары сатып алу) килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү, смета, техник күзәтчелек һәм документлар өчен түләү)

«РИЗА» «КАРШЫ»

3. Гражданнар җыенын үткәрү өчен, торак пунктта яшәүчеләрнең исемлеген территориаль билге буенча (урамнар буенча) бүләргә.

4. Гражданнар җыеннын үткәрүгә җаваплы итеп Починок Кучук авыл җирлеге башкарма комитететын билгеләргә.

5. Әлеге карарны кабул ителгән көннән соң 5 көн эчендә мәгълүмат стендларында һәм Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында «Авыл җирлекләре» бүлегендә урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә.

6. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Починок-Кучук авыл җирлеге башлыгы Р.Ә. Гыйниятов